**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«18» 11 2021 ел Яр Чаллы № 4185

Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге спорт объектларын, шул исәптән укудан тыш вакытта мәгариф учреждениеләренең спорт инфраструктурасын халык тарафыннан куллану тәртибен раслау турында

Тукай муниципаль районы халкының барлык төркемнәренең сәламәтлек саклау һәм ныгыту ихтияҗларын канәгатьләндерү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, массакүләм, системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру, актив яшәү рәвешенә тарту максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге спорт объектларын, шул исәптән укудан тыш вакытта мәгариф учреждениеләренең спорт инфраструктурасын халык тарафыннан куллану тәртибен расларга (1кушымта).
2. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казан учреждениесенә 3 эш көне эчендә әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 18.11.2021 № 2185 номерлы карарына кушымта

## Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге спорт объектларын, шул исәптән укудан тыш вакытта мәгариф учреждениеләренең спорт инфраструктурасын халык тарафыннан куллану тәртибе

1. Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге спорт объектларын, шул исәптән укудан тыш вакытта мәгариф оешмаларының спорт инфраструктурасын халык тарафыннан куллануның әлеге тәртибе физик культура һәм спорт белән массакүләм шөгыльләнү өчен шартлар тудыру максатыннан эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль берәмлеге карамагындагы спорт учреждениеләренең биналарыннан (мәйданнарыннан, спорт корылмаларыннан, ярдәмче бүлмәләрдән) укудан тыш вакытта (дәресләр һәм чаралар үткәрүдән буш вакытта, шул исәптән каникул, ял һәм бәйрәм көннәрендә) файдалану механизмын билгели.

2. Әлеге Тәртиптә тиешле билгеләмәләр белән түбәндәге терминнар кулланыла:

**спорт чарасы -** Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль берәмлеге ведомствосындагы учреждениеләр территорияләрендә һәм спорт корылмалары эчендә үткәрелә торган теләсә нинди даими булмаган чара;

**физкультура-сәламәтләндерү хезмәте -** кулланучының сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, физик тернәкләндерү һәм физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт ялын үткәрүдә ихтыяҗларын канәгатьләндерү буенча башкаручы эшчәнлеге;

**спорт хезмәте -** кулланучының спорт нәтиҗәләренә ирешү ихтыяҗларын канәгатьләндерү буенча башкаручы эшчәнлеге;

**хезмәт алучы -** Россия Федерациясе гражданнары (муниципаль берәмлек халкы һәм кунаклары), оештырылган төркемнәр (балалар, яшүсмерләр, өлкән яшьтәге кешеләр, ветераннар, физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр һ. б.) һәм сәламәтлек саклау һәм ныгыту, авыруларны профилактикалау, эшкә югары сәләтлелекне тәэмин итү, спорт-тамаша, мәдәни-массакүләм һәм күңел ачу-уен чараларында катнашып, актив ял итү һәм буш вакытны уздыру өчен, физик күнегүләр һәм спорт белән шөгыльләнергә теләүче юридик зат формасында теркәлгән оешмалар;

**хезмәтне башкаручы -** Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль берәмлеге ведомствосындагы учреждениеләр (алга таба - учреждениеләр);

**спорт объекты -** физик культура дәресләре үткәрү, спорт юнәлешендәге дәресләр: тренировкалар, спорт уеннары, спорт ярышлары, башка чаралар уздыру, шул исәптән халыкка физик культура һәм спорт белән мөстәкыйль шөгыльләнү өчен ачык яссылык спорт корылмаларына керү мөмкинлеге бирү юлы белән дә файдаланыла ала торган объектлар. Учреждениеләрнең төп спорт объектларына (спорт билгеләнешендәге объектларга) түбәндәгеләр керә: спорт залы, тренажер залы, бию залы, йөгереш юлы, урам тренажерлары булган мәйданчыклар һ.б.

3. Учреждениеләр халыкның физкультура-спорт инфраструктурасын куллану

күләмнәре турында мөстәкыйль рәвештә түбәндәге принциплар нигезендә карар кабул итәләр:

1) учреждениеләрнең төп устав эшчәнлеген (тренировкалар, белем бирү процессы) тулы күләмдә тәэмин итү зарурлыгын, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү максатында файдалану өчен спорт объектларын бирү турында төзелгән шартнамәләрне үтәү зарурлыгын исәпкә алып, халык тарафыннан спорт объектларын максималь файдалануны тәэмин итү;

2) законнарда билгеләнгән куркынычсызлык таләпләрен үтәү.

4. Учреждениеләрнең спорт объектлары халык тарафыннан учреждениеләрнең төп эшчәнлегенә зыян китереп файдаланыла алмый.

5. Халык тарафыннан спорт объектларын куллану түбәндәге ысуллар белән башкарыла:

1) учреждениеләренең локаль норматив актлары нигезендә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү максатында спорт объектларын файдалануга бирү буенча хезмәт күрсәтү;

2) халыкка физик культура һәм спорт белән мөстәкыйль шөгыльләнү өчен ачык яссылык спорт корылмаларына керү мөмкинлеген бирү.

6. Учреждениеләр халык тарафыннан спорт объектларын куллану графигын билгели.

7. Спорт чарасын үткәрүне планлаштыручы чит оешма, физик затлар төркеме чараны үткәрү датасын, вакытын һәм урынын тиешле учреждение җитәкчесе белән 2 атнадан да соңга калмыйча килештерергә һәм учреждениеләренең спорт объектлары биналарын (мәйданнарны, спорт корылмаларын, ярдәмче бүлмәләрне) бушлай, ташламалы яки түләүле нигездә файдалануга гражданнар, шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар белән РФ законнарында каралган тәртиптә милекче һәм гамәлгә куючы ризалыгы белән шартнамә төзергә тиеш.

8. Балигъ булмаган килүчеләрнең оештырылган төркеменә спорт объектларының биналарына исемлекләр буенча, өлкәннәр (төркем өчен җаваплы зат) озатуында керегә рөхсәт ителә. Балигъ булмаганнар төркеме исемлеге балаларның фамилиясен, исемен, атасының исемен, уку урынын, шулай ук аларны озатучы өлкән яшьтәге, төркем өчен җаваплы затның исемен, фамилиясен, атасының исемен, паспорт мәгълүматларын, эш (уку) урынын, яшәү урынын һәм элемтә телефонын үз эченә алырга тиеш.

9. Тиешле шартнамә төземичә генә чараны мөстәкыйль үткәрү тыела. Килештерелмәгән чара үткәрү факты ачыкланганда, тиешле учреждение администрациясе чараны туктатырга һәм анда катнашучыларның барысын да учреждение территориясеннән чыгарырга хокуклы.

10. Учреждениеләр, халык тарафыннан спорт объектларыннан файдаланганда, шул исәптән физик культура һәм спорт белән мөстәкыйль шөгыльләнү өчен халыкка ачык яссылык спорт корылмаларына керү юлы белән дә, спорт объектының закон тарафыннан билгеләнгән куркынычсызлык таләпләрен үтәүне контрольдә тота.